**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2152**
**08.05.2020**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлегенә үзгәреш кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2016 елның 13 маендагы 2363 номерлы карары (Башкарма комитетның 2016 елның 24 июнендәге 3237 номерлы, 2016 елның 13 декабрендәге 6675 номерлы, 2017 елның 8 февралендәге 588 номерлы, 2017 елның 3 маендагы 2747 номерлы, 2017 елның 28 сентябрендәге 5805 номерлы, 2018 елның 18 июлендәге 4000 номерлы, 2018 елның 27 июлендәге 4226 номерлы, 2018 елның 2 августындагы 4343 номерлы, 2018 елның 22 ноябрендәге 6940 номерлы, 2019 елның 5 мартындагы 1144 номерлы, 2019 елның 23 маендагы 2663 номерлы, 2019 елның 8 ноябрендәге 5755 номерлы, 2020 елның 7 февралендәге 545 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлегенә, 25 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«25) җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан файдаланучыларга мәгълүмат бирү.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов